■ Дин вә гавәм

# КОРЪӘН ТЕЛЕ – ҮЗЕ БЕР МОГҖИЗА

Интернеттан "Коръән археологиясе" дип эзләсәгез, берни дә тапмассыз. "Библия археологиясе" бар. "Коръән археологиясе" соңгы ун елда гарәп илләрендә алып барылган археологик эзләнүләр нәтиҗәсендә күптән түгел барлыкка килгән яңа өлкә.

Санкт-Петербург дәүләт университеты профессоры, Россия Фәннәр академиясе мөхбир - әгъзасы, 250 дән артык фәнни эш авторы, Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский бер лекциясен әнә шундый сүзләр белән башлап җибәрде. Алга таба археологик табышлар белән кыскача таныштыра барып, гарәпләрнең борынгы заман тарихына экскурсия ясады ул. Лекция кысаларында Коръәндә язылганнар аша кешелек тарихы һәм ислам мәдәнияте бәйләнеше турында сөйләде. Коръәннән өзекләр сакланган, "Кешеләр арасыннан Пәйгамбәр килде", "Безнең Алла, сезнең алла - бер Алла" дигән сүзләр язылган борынгы гарәп язу үрнәкләренә аерым тукталды.

"Вакыт-вакыт гарәп ярымутравында дөньякүләм монополиягә ия әйберләр барлыкка килгән - нефть, аңа кадәр кофе, аннан да алдарак бөтен өлкәдә кулланыла торган хуш исле әйберләр (антисептика, косметика, дару, дини йолаларны үтәүдә киң файдаланугa кергән матдәләр) һәм бакыр. Бөтен тарих, алгарыш, вәзгыять исламга китерә", - диде ул.

Әлбәттә, әгәр дә чарада дин әһелләре катнашкан булса фән эшлеклесенең лекция вакытында яңгыраткан кайбер сүзләренә бәйле рәвештә үзара бәхәсләр дә туган булыр иде. Лекторны тыңлаган студентлар, яшь галимнәр арасыннан исә аның белән бәхәскә керергә батырчылык итүче булмады. Бары тик өлкән яшьтәге берничә галимебез генә Пиотровскийның Коръәнгә карата шәхси мөнәсәбәтен белергә теләгәндәй 2-3 сорау юллап чикләнде. Аларга җавап рәвешендә ул: "Коръән төрле халыклар, пәйгамбәрләр, цивилизацияләрнең тарихый фәлсәфәсен сыйдырган изге язу. Кешелек Коръәннән соң аңар охшаш берни дә барлыкка китерә алмый. Бу үзе үк аның илаһилыгы турында күрсәтә. Исламга кадәр гаҗәпкә калдыра торган гарәп шигърияте булган. Әмма ул да, аннан соңгы шигърият, әдәбият та, вәгазьләр дә бөтенләй башка. Коръән теле үзе бер могҗиза", - диде.

Нәрсә ул дога?

Дога, мөселман кешесенең тормышында зур әһәмияткә ия. Ул Аллаһ тәгаләгә тәүхид белән бәйле. Дога - ул, Аллаһ тәгаләгә үзенең мескенлегенә, мохтаҗлыгыңны күрсәтеп, Аннан башка көч-куәт иясе юклыгын белдереп, үзеңә файдалы нәрсәләрне һәм зарарлы нәрсәләрдән саклауны сорау.

Шуңа да, дога губудиянның - Аллаһка коллыкны күрсәтүнең иң югары дәрәҗәләреннәндер. Дога белән кеше үзенең түбән, зәгыйфь вә мескен зат икәнлеген тоя һәм Раббысыннан ярдәм өмет итә.

Доганың фазыйләтләре, җимешләре һәм серләре:

1) Дога - ул, Аллаһка итагатьлелек һәм Аның кушканнарын үтәү. Чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде: "Раббыгыз әйтте: "Миңа ялварыгыз! Мин сезгә җавап бирермен".

2) Дога - ул, гыйбадәт. Бу хакта пәйгамбәребез үзенең хәдисшарифендә болай диде: "Дога - ул, гыйбадәт"

3) Дога тәкәбберлектән пакьлый: "Раббыгыз әйтте: "Миңа ялварыгыз! Мин сезгә җавап бирермен". Әмма, Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр түбәнсетелгән вә хур булган хәлдә җәһәннәм утына керерләр".

4) Дога, Аллаһ тәгалә каршында иң хөрмәтле нәрсә, чөнки дога гыйбадәтнең иң югары өлеше, ә Аллаһ кешеләрне вә җеннәрне бер үзенә генә гыйбадәт кылыр өчен яратты. Пәйгамбәребез әйтте: "Аллаһ тәгалә каршында догадан да хөрмәтлерәк нәрсә юк"

5) Дога, Аллаһ тәгаләнең ачуыннан саклануга сәбәп. Пәйгамбәребез әйтте: "Кем Аллаһ тәгаләгә дога кылмый икән, Ул аңа ачулана".

6) Дога, Аллаһ каршында күркәмле киң ача, һәм тәвәккәллеккә вә йөрәкнең бер Аңа гына бәйләнүенә, башка затлардан, кешеләрдән азат булуына сәбәп була. Ибен Тәймия рахимәһуллаһ болай диде: "Адәм баласы үзенең хаҗәтләрен үтәүдә һәм зарарлардан саклануда Аллаһның рәхмәтенә теләге арткан саен, ул кешенең Раббысы каршында губудиясе (итагатьлеге вә коллыгы) арта һәм Аллаһтан башка нәрсәләрдән үзен азат вә ирекле хис итә башлый. Ләкин, әгәр адәм баласының теләге кешеләр вә башка мәхлуклар белән бәйле булса (фәлән кеше генә миңа ярдәм итә ала, аннан гына ярдәм сорарга кирәк, дигән кебек), ул вакытта аның йөрәге шул мәхлук белән бәйле булып, аның колы була".

7) Дога, гаҗизлектән саклый. Пәйгамбәребез әйтте: "Иң гаҗиз кеше - дога кылудан гаҗиз булганы, һәм иң саран кеше - сәлам бирүгә саран булганы"

8) Доганың җимеше тәэмин ителгән, иншәАллаһ. Пәйгамбәребез әйтте: "Кемдә кем гөнаһлы эшләр яки туганлык җепләрен өзүне сорамыйча, башка нинди генә булса да нәрсәне сорап Аллаһка дога кыла икән, Аллаһ аңа сораганын бирә, яки шуңа тиң булган явызлыктан саклый".

Пәйгамбәребез әйтте: "Мөэмин Аллаһ тәгаләдән нәрсә генә сорамасын, һичшиксез Аллаһ аның сораганын бу дөньяда бирер, яки инде аңа ахирәткә калдырыр, әгәр дә ул сораганын ашыктырмаса".

Пәйгамбәребездән сорадылар: "Ашыктыру нәрсә була, әй Аллаһның расүле?", - дип. Әйтте: "Дога кылучы әйтер: мин дога кылдым, кылдым, әмма ләкин кабул булуын күрмәдем". Бу ике хәдистә мөселман кешесенең догасы юкка чыкмаганлыгы бәян ителә.

Ибен Хәҗәр болай диде: "һәрбер дога кабул була, ләкин аның кабуллыгы төрлечә; кайвакыт соралган нәрсә кабул булса, ә кайвакыт инде шуңа тиң әйбер бирелә".

**Доганың шартлары:**

Дога кабул булсын өчен берничә шарт бар, ошбу шартлар үтәлгәндә генә дога кабул була, иншәАллаһ. Без шушы шартларның иң мөһимнәрен искә алып узарбыз:

1) Дога кылучы, бер Аллаһ кына аның догасын кабул итәргә кадир икәнлеген белергә тиеш.

2) Аллаһтан башкага дога белән ялвармаска тиеш. Чөнки Аллаһтан башкага дога кылу ширеккә керә.

3) Аллаһ тәгаләгә тәвәссүл кылганда (якынаю юлы эзләгәндә), шәригать буенча рөхсәт ителгән тәвәссүлне генә кулланырга тиеш. Мәсәлән, Аллаһның күркәм исемнәре, яки камил сыйфатлары белән. Шулай ук, үзенең кылган изге гамәлләре яки исән булган вә көче җиткән изге-салих бәндәнең аның өчен дога кылуын сорап һ.б.

4) Доганың кабуллыгында ашыктырудан читләшергә тиеш.

5) Яхшы нәрсә сорап кына догa кылырга тиеш.

6) Аллаһ тәгалә хакында фәкать яхшы гына уйларга тиеш.

7) Йөрәге вә күңеле белән сорарга тиеш.

8) Хәләл ризык кына ашарга тиеш.

9) Мөселманнарга дошманлыктан читләшергә тиеш.

***"Догаң кабул булсын дисәң!"***
**Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи.**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлкағиҙә-Зөлхизә 2013 миләди йыл**
**1434 һижри йыл.**

| Зөлкағиҙә Зөлхиҙә | Аҙна көндәре | Август, Сентябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Дүшәмбе | 16 | 6.22 | 7.52 | 14.30 | 18.58 | 20.28 | 21.58 |
| 11 | Шишәмбе | 17 | 6.24 | 7.54 | 14.30 | 18.57 | 20.26 | 21.57 |
| 12 | Шаршамбы | 18 | 6.26 | 7.56 | 14.30 | 18.53 | 20.23 | 21.53 |
| 13 | Кесе йома | 19 | 6.27 | 7.57 | 14.30 | 18.51 | 20.21 | 21.51 |
| 14 | Йома | 20 | 6.29 | 7.59 | 14.30 | 18.48 | 20.18 | 21.48 |
| 15 | Шәмбе | 21 | 6.31 | 8.01 | 14.30 | 18.45 | 20.15 | 21.45 |
| 16 | Йәкшәмбе | 22 | 6.33 | 8.03 | 14.30 | 18.43 | 20.13 | 21.43 |
| 17 | Дүшәмбе | 23 | 6.35 | 8.05 | 14.30 | 18.40 | 20.10 | 21.40 |
| 18 | Шишәмбе | 24 | 6.37 | 8.07 | 14.30 | 18.38 | 20.08 | 21.38 |
| 19 | Шаршамбы | 25 | 6.39 | 8.09 | 14.30 | 18.35 | 20.05 | 21.35 |
| 20 | Кесе йома | 26 | 6.40 | 8.10 | 14.30 | 18.33 | 20.03 | 21.33 |
| 21 | Йома | 27 | 6.42 | 8.12 | 14.30 | 18.30 | 20.00 | 21.30 |
| 22 | Шәмбе | 28 | 6.44 | 8.14 | 14.30 | 18.28 | 19.58 | 21.28 |
| 23 | Йәкшәмбе | 29 | 6.46 | 8.16 | 14.30 | 18.25 | 19.55 | 21.25 |
| 24 | Дүшәмбе | 30 | 6.48 | 8.18 | 14.30 | 18.23 | 19.53 | 21.23 |
| 25 | Шишәмбе | 1 | 6.50 | 8.20 | 14.30 | 18.20 | 19.50 | 21.20 |
| 26 | Шаршамбы | 2 | 6.52 | 8.22 | 14.30 | 18.18 | 19.48 | 21.18 |
| 27 | Кесе йома | 3 | 6.54 | 8.24 | 14.30 | 18.15 | 19.45 | 21.15 |
| 28 | Йома | 4 | 6.55 | 8.25 | 14.30 | 18.12 | 19.43 | 21.12 |
| 29 | Шәмбе | 5 | 6.57 | 8.27 | 14.30 | 18.101 | 19.40 | 21.10 |
| 30 | Йәкшәмбе | 6 | 6.59 | 8.29 | 14.30 | 8.08 | 19.38 | 21.08 |
| 1 | Дүшәмбе | 7 | 7.01 | 8.31 | 14.30 | 18.05 | 19.35 | 21.05 |
| 2 | Шишәмбе | 8 | 7.03 | 8.33 | 14.30 | 18.03 | 19.33 | 21.03 |
| 3 | Шаршамбы | 9 | 7.05 | 8.35 | 14.30 | 18.00 | 19.30 | 21.00 |
| 4 | Кесе йома | 10 | 7.07 | 8.37 | 14.30 | 17.58 | 19.28 | 20.58 |
| 5 | Йома | 11 | 7.09 | 8.39 | 14.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 6 | Шәмбе | 12 | 7.11 | 8.41 | 14.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 7 | Йәкшәмбе | 13 | 7.13 | 8.43 | 14.30 | 17.501 | 19.20 | 20.50 |
| 8 | Дүшәмбе | 14 | 7.15 | 8.45 | 14.30 | 7.48 | 19.18 | 20.48 |
| 9 | Шишәмбе | 15 | 7.17 | 8.47 | 14.30 | 17.46 | 19.16 | 20.46 |

■ Ә сез беләсезме?

# ДОГА ШАРТЛАРЫ

**Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ**

Моннан бер ел тирәсе элек бер мөселманның "Фейсбук" тагы язмасы хәтергә кереп калды...

"Мин, - ди ул, - бер атеист белән бер бүлмәдә эшлим. Берчак безнең буш вакытыбыз барлыкка килде һәм, вакыт уздыру өчен чүп чиләген баскетбол кәрзине итеп, кәгазьдән ясалган "туп"ны шунда ыргытып уйный башладык. Җан-фәрманга тырышабыз икебез дә, әмма уңыш берәүгә дә елмаймый. Шуннан атеист-коллега: "Дога кылып кара, файдасы тимәсме", - дип миннән көлә башлады.

Мин, аз гына да уңайсызланып тормыйча, кычкырып дога кылдым һәм "туп"ны кәрзингә ыргыттым, ул бик җиңел генә чүп чиләгенең төбенә төшеп утырды. Хезмәттәшем, сер бирмәскә тырышып, минем арттан туп ыргыту хәрәкәтен кабатлады. Тик уңыш аңа күпме тырышса да елмаймый иде. "Туп"ның траекториясен формулага куеп исәпләп карый (ул сәләтле математик), тегеләй дә, болай да тырыша - "туп" кына "буйсынмый". Мондый очракта һәр атеист, әлбәттә, уңышны очраклылыкка сытлый, Аллаһы Тәгалә белән туры элемтәнең серле көчен инкарь итә. Бары тик Аллаһы Тәгаләгә ялварып җавап алырга күнеккән мөэминнәр генә дога өчен пространство дигән киртәнең юклыгын, кабул булган теләкләрнең тормыштагы вакыйгаларны 180 градуска борырга сәләтле булуын, "дога - мөэминнең коралы" икәнен яхшы белә.

Доганың, әлбәттә, үз шартлары бар. Галәмнәрнең хуҗасы кайвакыт, безгә билгеле булмаган сәбәпләр аркасында, доганы кире кайтарырга, дога юлына пәрдә куярга мөмкин. Кайвакыт дога кабул булып та, ялваручы бу хакта белмичә кала, чөнки дога белән җавап арасында дистә еллар узарга да ихтимал, кайбер догаларның җавабына мөэмин бары тик ахирәттә генә юлыга. Соңгысы мөселман өчен иң хәерлесе, чөнки ахирәттәге әҗер - иң кыйммәтлесе. Догаларны кабул булудан тыя торган безгә билгеле җиде сәбәп бар, сораганга җавап алырга теләүчеләр бу сәбәпләрне яхшылап өйрәнергә һәм үзләрендәге кимчелекләрдән арыну юлында армый-талмый тырышырга тиешләр. Бу язмада без аларны санап тормабыз, укучыны бары тик берничә гыйбрәтле риваять белән генә таныштырырбыз. Беренчесе - имам Әхмәд һәм ипи пешерүче вакыйгасы безгә (ихлас дога кабул булсын) кирәкле мөһим бер шартны шәрехли.

Бервакыт имам Әхмәд (Аллаһ аннан риза булсын) сәфәрдә вакытта кунып чыгар өчен мәчеткә юнәлә. Әмма мәчет сакчысы, күпме генә үтенеп сораса да, имамны кунарга кертми. Өметен өзгән имам мәчет бусагасы янында төн уздырырга ниятли. Тик моны белеп ярсыган сакчы аны якасыннан эләктереп ала һәм мәчеттән ераккарак өстерәп алып китә. Мәчет янында гына яшәгән икмәк пешерүче моны күреп тора һәм, ярдәмчесез картны кызганып, үз өенә төн кунарга чакыра. Икмәк пешерүче йортында имам Әхмәд карап утыра: хуҗа үзе ипи баса, үзе һәр хәрәкәте саен: "Әстәгъфируллаһ", - дип Аллаһы Тәгаләдән кичерү сорый. Төн шулай үза.

Иртәгесен Әхмәд икмәк пешерүченең гамәлләренең сәбәбен сорый. Тегесе моның инде үзе өчен гадәткә әйләнүен, һәрвакыт шулай эшләвен әйтә. Имам Әхмәд: "Бу эшеңнең берәр нәтиҗәсе бармы соң, берәр ничек бүләкләнгәнең бармы?" - дип сорый. Икмәк пешерүче: "Аллаһ белән ант итәм, бер догамнан башка барлык догаларга да җавап алмыйча калганым булмады", - дип җавап бирә. "Нинди догаңа җавап юк соң?" - ди Әхмәд. "Бөек имам Әхмәдне күрәсем килә, шуны күрә алмадым әлегә чаклы", - дигән җавап ишетә. "Мин имам Әхмәд, - дип кычкырып җибәрә имам. - Аллаһ белән ант итәм, мине синең догаңа җавап итеп бусагаңа өстерәп китереп ташладылар". Дога кабул булсын өчен, Аллаһ каршында гөнаһлардан даими кичерү сорап, тәүбә итеп торуның мөһимлеген җиткерә безгә бу риваять.

Доганың кабул булмавында да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте чагылырга мөмкин, чөнки бәндә кайчак үзе өчен зыянлы нәрсәне сорый. Бу уңайдан Гайсә пәйгамбәрнең бу теләктән баш тартырга өндәвенә, моның ул кеше өчен зыянлы булуы ихтималлыгына карамастан, үҗәтләнеп үз сүзендә торган бәндә дога белән бәлагә юлыга. Гайсә галәйһиссәлам өйрәткән доганы ул юл буенда аунап яткан сөякләрдә сынап карарга уйлый. Сөякләр арысланныкы булып чыга, терелеп торып баскан арыслан үзен терелтү догасын кылган бәндәне өзгәләп ташлый. Шуңа күрә байлык сорап, Аллаһы Тәгалә мал бирми икән, көенергә кирәкми, димәк, малның артуы синең өчен зыянлы. Башка нәрсәләр белән дә шулай ук булуы ихтимал. Безнең заман чынбарлыгыннан бер мисал. Бер әни сөйли. Улы уен автоматында биш мең сум акча откач, тыелган мал булса да, әни кеше, кызыгып, Аллаһы Тәгаләдән улы өчен тагын да зуррак отыш сорап дога кыла. Хакыйкатьтер: әниләр догасына пәрдә юк. Ананың догасы кабул була, улы зур суммада акча ота һәм җиңел килгән мал сәбәпле эчкечелеккә чыга. Хәзер инде эчкече улы белән интеккән ана үзенә бәла сораганын аңлый һәм үкенә. Дога кылсаң, уйлап кыл, хәерлесен кыл, үз башыңа һәлакәтлек сорама. Хәерле булмаган доганың бәла китерүенә тормышта мисаллар җитәрлек. Бигрәк тә тыелган нәрсәләрне сораудан сак булырга кирәк.

Дога кылучы тагын бер мөһим нәрсәне истә тотарга тиеш: әлеге процесс ике өлештән тора. Без сәбәп дөньясында яшибез, шуңа күрә күл күтәреп дога кылганнан соң, аякларны бөкләп утырып җавап көтү мәгънәсезлек булыр иде. Доганың икенче өлеше теләкләрне тормышка ашыручы гамәлләр белән мәшгүль булуны таләп итә. кәгазь "туп" кәрзингә керсен өчен, аны ыргытырга кирәк. Ыргытмый гына догам кабул булмады дип утыру ахмаклыкның югары дәрәҗәсе булыр иде.

Бер нәрсәгә шик юк: шарты килгән ихлас догага кайчан да булса бер җавап бирелмичә калмый, чөнки догаларның кабуллыгы - ул Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе.